ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 18 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасында муниципаль
берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына
Татарстан Республикасы территориясендә
гражданнарның аерым категорияләре өчен
җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез
дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү
өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен
бирү турында» Татарстан Республикасы
Законына кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару методикасы**

1. Әлеге Методика Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары (алга таба – муниципаль берәмлек) бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен исәпләп чыгару өчен каралган.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан i-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенцияләрнең планлаштырыла торган күләме юлда йөргән өчен j-төр шәһәр транспортында 50 тапкыр һәм аннан күбрәк юл йөрүләргә озак вакытка исәпләнелгән билетлар белән түләү өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән иң чик максималь тарифтан һәм шәһәр яны автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга бер пассажир/километрга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән иң чик максималь тарифтан, бер айда бердәй айлык социаль юл йөрү билеты һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта) буенча юлда йөрүләрнең айлык уртача санынннан, бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарның) бер айга исәпләгәндә сатылган уртача санынннан һәм бердәй айлык социаль юл йөрү билетының һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетының билгеләнгән бәясеннән (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарны тулыландыру бәясеннән) чыгып билгеләнә.

I-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C_i = (SUM\ (T_{гор.} x\ П_i)\ x\ 12\ ай\ ) + (T_{пр}\ x\ P_{i-пр})\ x\ 12\ ай) – B_{орг},$$

монда:

$C_i$ – i-муниципаль берәмлегенә бүлеп бирелә торган субвенция күләме;

$T_{гор}$ – юлда йөргән өчен j-төр транспортта 50 тапкыр һәм аннан күбрәк юл йөрүләргә озак вакытка исәпләнелгән билетлар белән түләү өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән иң чик максималь тариф;

$П_i$ – бер айда бердәй айлык социаль юл йөрү билеты һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта) буенча юлда йөрүләрнең тәмамланган соңгы календарь елда исәпләнгән айлык уртача саны;

$Т_{пр}$ – шәһәр яны автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга бер пассажир/километрга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән иң чик максималь тариф;

$P_{i\text{-пр}}$ – юлда йөргән өчен автоматлаштырылган түләү системасы (алга таба – система) операторлары белешмәләре буенча тәмамланган соңгы календарь елда йөрелгән пассажир/километрларның айлык уртача саны;

$В_{орг}$ – муниципаль берәмлектә бердәй айлык социаль юл йөрү билетларын һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетларын сатудан (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарны тулыландырудан) транспорт оешмаларының табышы.

3. Бердәй айлык социаль юл йөрү билеты яки балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта) буенча юлда йөрүләрнең айлык уртача саны түбәндәгечә исәпләнә:

i-муниципаль берәмлегендә юлда йөрүләрнең персональ исәбе алып барылганда – системаның тәмамланган соңгы календарь ел белешмәләреннән чыгып;

i-муниципаль берәмлегендә юлда йөрүләрнең персональ исәбе алып барылмаганда түбәндәге формула буенча:

$П_i = (Р_в + Р_д) \times 50$ юл йөрү,

монда:

$Р_в$ – муниципаль берәмлектә бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының тәмамланган соңгы календарь елда сатылган айлык уртача саны;

$Р_д$ – муниципаль берәмлектә балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының тәмамланган соңгы календарь елда сатылган айлык уртача саны.

4. Муниципаль берәмлектә бердәй айлык социаль юл йөрү билетларын һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетларын сатудан (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарны тулыландырудан) транспорт оешмаларының кереме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$В_{орг} = (Ц_в \times Р_в + Ц_д \times Р_д) \times 12$ ай,

монда:

$Ц_в$ – исәпләү чорында бердәй айлык социаль юл йөрү билетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән бәясе;

$Ц_д$ – исәпләү чорында балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән бәясе.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 07 ноябрь
№ 86-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ